| БАВЛИНСКИЙ<br>ГОРОДСКОЙ СОВЕТ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ<br>СОВЕТЫ |
|---|---|
| **РЕШЕНИЕ** | **КАРАР** |

11.04.2022 Баулы шәһәре №57

Татарстан Республикасы Баулы шәһәр Советының 2021 елның 18 февралендәге «Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә һәм физик һәм юридик затларның хосусый милкендәге җирләргә кермәгән Татарстан Республикасы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендәге яшел үсентеләрне кисү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында»гы 24 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Россия Федерациясе законы нигезендә Баулы шәһәр Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә һәм физик һәм юридик затларның хосусый милкендәге җирләргә кермәгән Татарстан Республикасы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендәге яшел үсентеләрне кисү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында»гы 24 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.4 пунктны төшереп калдырырга;

3.3. пунктының җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Киселергә тиешле агач-куак үсемлекләренең санын, төрен, категориясен билгеләү максатында яшел үсентеләрне табигый техник тикшерү акты;

3.3. пунктына түбәндәге эчтәлекле унберенче абзац өстәргә:

«- исәбе Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Урман ресурслары күләме берәмлеге өчен һәм федераль милектәге урман кишәрлеге мәйданы берәмлеге

өчен түләү ставкалары турында» 2007 елның 22 маендагы 310 номерлы карары нигезендә киселгән агач материалының хакын (хакын) исәпләп чыгару;

3.11. пунктта «рөхсәт ителергә мөмкин» сүзләрен «рөхсәт ителә» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 3.18 пункт өстәргә:

«3.18. Агач һәм куакларны кисүгә, ябалдашларын кисүгә яисә утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең стандарты һәм тәртибе Татарстан Республикасы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлегенең башкарма комитеты раслаган административ регламент белән билгеләнә.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы шәһәр Советының Законлылык, хокук тәртибе, спорт һәм яшьләр мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Баулы шәһәре Мэры урынбасары,
шәһәр Советы Рәисе урынбасары К.Ф. Корбанов